**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
11 марта 2016 года

**Статья 1**

Внести в Бюджетный кодекс Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II часть), № 10 (I часть), № 12 (IV часть); 2006, № 6 (I часть), № 12 (I часть); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III часть), № 10 (I часть); 2009, № 7 – 8 (I часть), № 12 (I часть); 2010, № 7 (II часть), № 12 (I часть); 2011, № 8 (I часть), № 11 (I часть), № 11 (II часть); 2012, № 11 (I часть); 2013, № 7, № 10, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 12 (III часть); 2015, № 7 (I часть), № 8 – 9) следующие изменения:

1) пункт 6 статьи $20^1$:

а) дополнить словами «, за исключением случая, указанного в абзаце втором настоящего пункта»;

б) дополнить абзацем следующего содержания:

«При исполнении бюджета Республики Татарстан, бюджета Территориального фонда обязательного медицинского страхования Республики Татарстан допускается предоставление бюджетных инвестиций в объекты государственной собственности Республики Татарстан, указанные в абзаце первом настоящего пункта, в случае изменения в установленном порядке типа государственного бюджетного или автономного учреждения или организационно-правовой формы государственного унитарного предприятия, являющихся получателями субсидий, предусмотренных статьей $20^{1.2}$ настоящего Кодекса, на государственное казенное учреждение после внесения соответствующих изменений в решение о предоставлении субсидий на осуществление капитальных вложений в указанные объекты с внесением соответствующих изменений в ранее заключенные государственным бюджетным или авто-

номным учреждением, государственным унитарным предприятием договоры в части замены стороны договора – государственного бюджетного или автономного учреждения, государственного унитарного предприятия на государственное казенное учреждение и вида договора – гражданско-правового договора государственного бюджетного или автономного учреждения, государственного унитарного предприятия на государственный контракт.»;

2) в статье $20^{1.2}$:

а) пункт 5 дополнить абзацем следующего содержания:

«В случае признания в соответствии с настоящим Кодексом утратившими силу положений закона Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан на текущий финансовый год и плановый период, закона Республики Татарстан о бюджете Территориального фонда обязательного медицинского страхования Республики Татарстан на текущий финансовый год и плановый период в части, относящейся к плановому периоду, государственное бюджетное или автономное учреждение, государственное унитарное предприятие вправе не принимать решение о расторжении предусмотренных настоящим пунктом договоров, подлежащих оплате в плановом периоде, при условии заключения дополнительных соглашений к указанным договорам, определяющих условия их исполнения в плановом периоде.»;

б) пункт 7:

дополнить словами «, за исключением случая, указанного в абзаце втором настоящего пункта»;

дополнить абзацем следующего содержания:

«При исполнении бюджета Республики Татарстан, бюджета Территориального фонда обязательного медицинского страхования Республики Татарстан допускается предоставление субсидий на осуществление капитальных вложений в объекты государственной собственности Республики Татарстан, указанные в абзаце первом настоящего пункта, в случае изменения в установленном порядке типа государственного казенного учреждения, являющегося государственным заказчиком при осуществлении бюджетных инвестиций, предусмотренных статьей $20^{1}$ настоящего Кодекса, на государственное бюджетное или автономное учреждение или изменения его организационно-правовой формы на государственное унитарное предприятие после внесения соответствующих изменений в решение о подготовке и реализации бюджетных инвестиций в указанные объекты с внесением изменений в ранее заключенные государственным казенным учреждением государственные контракты в части замены стороны договора – государственного казенного учреждения на государственное бюджетное или автономное учреждение, государственное унитарное предприятие и вида договора – государственного контракта на гражданско-правовой договор государственного бюджетного или автономного учреждения, государственного унитарного предприятия.»;

3) пункт 4 статьи $47^{1}$:

а) после слов «главными администраторами бюджетных средств» дополнить словами «, не являющимися органами, указанными в пункте 2 статьи 98 настоящего Кодекса,»;

б) дополнить абзацем следующего содержания:

«Главные администраторы средств бюджета Республики Татарстан, главные администраторы средств местного бюджета, не являющиеся органами, указанными в пункте 2 статьи 98 настоящего Кодекса, обязаны предоставлять информацию и документы, запрашиваемые соответственно Министерством финансов Республики Татарстан, органом муниципального финансового контроля, являющимся органом (должностными лицами) местной администрации, в целях осуществления полномочия по проведению анализа осуществления главными администраторами бюджетных средств внутреннего финансового контроля и внутреннего финансового аудита.»;

4) в подпункте 1 пункта 2 статьи 78 слова «бюджетных обязательств» заменить словами «и учет бюджетных и денежных обязательств»;

5) в абзаце третьем пункта 4 статьи 97 слова «в соответствии с отчетом о расходах бюджета, которому они были ранее предоставлены, сформированного в порядке, установленном главным администратором средств бюджета Республики Татарстан, и представленного не позднее 30 календарных дней со дня поступления указанных средств в бюджет Республики Татарстан» заменить словами «не позднее 30 рабочих дней со дня поступления указанных средств в бюджет Республики Татарстан, в соответствии с отчетом о расходах соответствующего бюджета, источником финансового обеспечения которых являются указанные межбюджетные трансферты, сформированным и представленным в порядке, установленном главным администратором средств бюджета Республики Татарстан»;

6) абзац второй пункта 2 статьи 101 дополнить словами «, права и обязанности должностных лиц Министерства финансов Республики Татарстан, права и обязанности объектов контроля (их должностных лиц), в том числе по организационно-техническому обеспечению проверок, ревизий и обследований, осуществляемых должностными лицами Министерства финансов Республики Татарстан».

**Статья 2**

В части 3 статьи 2 Закона Республики Татарстан от 4 июля 2009 года № 27-ЗРТ «О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан и признании утратившими силу отдельных положений актов бюджетного законодательства Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 7 – 8 (I часть); 2010, № 7 (II часть); 2011, № 11 (II часть) слова «1 января 2017 года» заменить словами «1 января 2018 года».

**Статья 3**

Положения статьи 18[1] Бюджетного кодекса Республики Татарстан применяются к правоотношениям, возникающим при составлении и исполнении бюджета Республики Татарстан, начиная с бюджета Республики Татарстан на 2017 год и на плановый период 2018 и 2019 годов.

**Статья 4**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
26 марта 2016 года
№ 13-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 мартында
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $20^{1}$ статьяның 6 пунктында:
а) “бюджет инвестицияләре” сүзләре алдыннан “, әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш,” сүзләрен өстәргә;
б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
“Әлеге Кодексның $20^{1.2}$ статьясында каралган субсидияләрне алучы булган дәүләт бюджет яисә автоном учреждениесе төрен йә дәүләт унитар предприятиесенең оештыру-хокукый рәвешен билгеләнгән тәртиптә дәүләт казна учреждениесе итеп үзгәрткән очракта, күрсәтелгән объектларга капитал салуларны гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү турындагы карарга тиешле үзгәрешләр кертелгәннән соң, дәүләт бюджет яисә автоном учреждениесе, дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан элек төзелгән шартнамәләргә шартнамәнең бер ягын – дәүләт бюджет яисә автоном учреждениесен, дәүләт унитар предприятиесен дәүләт казна учреждениесенә һәм шартнамәнең төрен – дәүләт бюджет яисә автоном учреждениесенең, дәүләт унитар предприятиесенең граждан-хокук шартнамәсен дәүләт контрактына алмаштыру өлешендә тиешле үзгәрешләр кертеп, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт милке

объектларына Татарстан Республикасы бюджетын, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетын үтәгәндә бюджет инвестицияләре бирү рөхсәт ителә.";

2) $20^{1.2}$ статьяда:

а) 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Әлеге Кодекс нигезендә агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы, агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты хакындагы Татарстан Республикасы законы нигезләмәләре план чорына караган өлешендә үз көчләрен югалткан дип танылган очракта, дәүләт бюджет яисә автоном учреждениесе, дәүләт унитар предприятиесе план чорында түләнергә тиешле әлеге пунктта каралган шартнамәләрне өзү турында карарны, күрсәтелгән шартнамәләргә аларны план чорында үтәү шартларын билгеле торган өстәмә килешүләр төзелгән очракта, кабул итмәскә хокуклы.";

б) 7 пунктта:

"мөлкәт объектларына" сүзләреннән соң ", әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш," сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Әлеге Кодексның $20^{1}$ статьясында каралган бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда дәүләт заказчысы булган дәүләт казна учреждениесе төрен билгеләнгән тәртиптә дәүләт бюджет яисә автоном учреждениесе итеп үзгәрткән йә аның оештыру-хокукый рәвешен дәүләт унитар предприятиесе итеп үзгәрткән очракта, күрсәтелгән объектларга бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турындагы карарга тиешле үзгәрешләр кертелгәннән соң, дәүләт казна учреждениесе тарафыннан элек төзелгән дәүләт контрактларына шартнамәнең бер ягын – дәүләт казна учреждениесен дәүләт бюджет яисә автоном учреждениесенә, дәүләт унитар предприятиесенә һәм шартнамәнең төрен – дәүләт контрактын дәүләт бюджет яисә автоном учреждениесенең, дәүләт унитар предприятиесенең граждан-хокук шартнамәсенә алмаштыру өлешендә үзгәрешләр кертеп, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт милке объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетын, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетын үтәгәндә субсидияләр бирү рөхсәт ителә.";

3) $47^{1}$ статьяның 4 пунктында:

а) "финанс контроле органнары" сүзләреннән соң "әлеге Кодексның 98 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән органнар булып тормаган" сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Әлеге Кодексның 98 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән органнар булып тормаган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары баш администраторлары, җирле бюджет акчалары баш администраторлары тиешенчә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, җирле администрация органы (вазыйфаи затлары) булып торучы муниципаль финанс контроле органы

тарафыннан бюджет акчалары баш администраторларының эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын башкаруына анализ ясау вәкаләтен гамәлгә ашыру максатларында соратып алына торган мәгълүматны һәм документларны бирергә тиеш.";

4) 78 статьяның 2 пунктындагы 1 пунктчада "бюджет йөкләмәләрен кабул итү" сүзләрен "бюджет һәм акча йөкләмәләрен кабул итү һәм аларның исәбен алып бару" сүзләренә алмаштырырга;

5) 97 статьяның 4 пунктындагы өченче абзацта "элек үзләренә бирелгән бюджет чыгымнары турында Татарстан Республикасы бюджеты акчалары баш администраторы билгеләгән тәртиптә һәм Татарстан Республикасы бюджетына күрсәтелгән акчалар кергән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча тапшырылган хисап нигезендә гамәлгә ашырыла" сүзләрен "финанс белән тәэмин итү чыганагы күрсәтелгән бюджетара трансфертлардан гыйбарәт тиешле бюджет чыгымнары турында Татарстан Республикасы бюджеты акчалары баш администраторы билгеләгән тәртиптә төзелгән һәм тапшырылган хисапка нигезләнеп, күрсәтелгән акчалар Татарстан Республикасы бюджетына кергән көннән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча" сүзләренә алмаштырырга;

6) 101 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацта "исемлеге" сүзеннән соң ", Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы вазыйфаи затларының хокуклары һәм бурычлары, контроль объектларының (аларның вазыйфаи затларының) хокуклары һәм бурычлары, шул исәптән аларның Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының вазыйфаи затлары үткәрә торган тикшерүләрне, ревизияләрне һәм тикшеренүләрне оештыру ягыннан һәм техник яктан тәэмин итү буенча хокуклары һәм бурычлары" сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

"Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында" 2009 елның 4 июлендәге 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 3 өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (II өлеш) "2017 елның 1 гыйнварына кадәр" сүзләрен "2018 елның 1 гыйнварына кадәр" сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $18^1$ статьясы нигезләмәләре, 2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетыннан башлап, Татарстан Республикасы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 26 марты
№ 13-ТРЗ